**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пунктында
2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2021 елның 19 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Ләке торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге уку йортлары студентларыннан кала яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Ләке авылы зират өчен бензокосилка сатып алу;

- Ләке авылы зираты коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

- Ләке авылында җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Ләке авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

- Ләке авылында чишмә территориясен төзекләндерү (килешү буенча төзелеш материаллары сатып алу);

- Ләке авылында территорияне һәм юл буе полосаларын чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Ләке  авылында өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлары сатып алу;

- Ләке авыл җирлегендә “Питрау” бәйрәме өчен призлар, бүләкләр алу

3.  Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән  халыкка җиткерергә,Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче ______________________ Шәрипова Л. И.